КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 11 февраль г.Казань № 135

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга кадәр һәм 2030 елга кадәрге чорга кластерга якын килү нигезендә Татарстан Республикасының җитештерү көчләрен үстерү һәм урнаштыру программасын раслау турында» 2008 ел, 22 октябрь, 763 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга кадәр һәм 2030 елга кадәрге чорга кластерга якын килү нигезендә Татарстан Республикасының җитештерү көчләрен үстерү һәм урнаштыру программасын раслау турында» 2008 ел, 22 октябрь, 763 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 26 сентябрь, 711 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы министрлыкларына, ведомстволарына һәм дәүләт комитетларына күрсәтелгән Программаны гамәлгә ашыру чараларын планнарга кертүне тәэмин итәргә.»;

3 пунктта «2015 елга кадәр» сүзләрен «2030 елга кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «2020 елга кадәр һәм 2030 елга кадәрге чорга кластерга якын килү нигезендә Татарстан Республикасының җитештерү көчләрен үстерү һәм урнаштыру» программасында:

Программа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2020 елга кадәр һәм 2030 елга кадәрге чорга кластерга якын килү нигезендә Татарстан Республикасының җитештерү көчләрен үстерү һәм урнаштыру программасы»;

2 бүлекнең 2.5 бүлекчәсендәге 2.5.1 нче таблицасыннан соң дүртенче абзацта «ФЗ-184 номерлы һәм ФЗ-131 номерлы федераль законнар» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар белән» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин